СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

4 июль, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№ 72 (8084)

Бәясе билгеләнгәнчә

## - Анонс -

### «Сызсыннар көмеш сабаннар...»

Район сабанчылары конкурсы турында язманы газетабызның 2 нче битеннән укыгыз.

Район сабанчылары конкурсы турында язманы газетабызның 2 нче битеннән укыгыз.

## БЕЗДӘН - ХЕЗМӘТ, ҖИРДӘН - ИКМӘК



Михаил Павлович өчен нефтьче һөнәре яңа түгел. Икенче ДНСка эшкә килүенә дә унике еллап инде. Станциядә техник җиһазлар ремонтлау буенча слесарь ул. Көн саен нинди генә деталь, узеллар белән эш итәргә дә, нинди өлешләргә «җан» кертергә туры килми аңа. Хәер, шул кадәр гомер бер урында хезмәт куйган һәм 5 нче разрядка ия булган кеше өчен бу эш әллә ни зур катлаулылык тудырмый. Моңа Михаил Павловичның намуслы, үҗәт булуын да кушсаң, эшнең ахыргы нәтиҗәсенең һәрчак бик әйбәт булуына нык ышанып була.

**Рәсемдә: НГДУ слесаре М.Просверкин.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

## ҺАВА ШАРТЛАРЫНА ГЫНА СЫЛТАРГА ЮК

### «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

**Бүген терлек азыгы хәзерләүдән дә көнүзәгрәк бурыч юк. Күпьеллык үләннәрне беренче кат чабып алып печән итү дә, сенажга тәгаенләнгән учатокларга тотыну да чиратка куеласы түгел. Ул эшләрнең беренчесен «Якты Күл» - дә, «Агрохимсервис»ның һәм шикәр заводының ярдәмче хуҗалыкларында аерча тиз тоттылар. Аларның беренчесендә июль башына 385 тонна коры печән запасы туплап куярга өлгерделәр, башка төр азыкларны да кушкач биредә бер шартлы терлеккә әзерләнгән азык бердәмлеге 3 центнерга җитте. Ә районда бу күрсәткечнең иң югарысы - 5 центнер азык берәмлеге - әлегә Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкта. Аларда коры печәнне пландагының 60 процентыннан күбрәк иттереп туплап куйдылар инде, әле чабыласы мәйданнары да бар. Мичурин исемендәге, «Кондырча», «Родина», «Әлмәт», Алга, «Комбайн» хуҗалыкларында бер шартлы терлеккә әзерләнгән азык берәмлеге 2 - 2,5 центнер тирәсе һәм аннан артыграк.**

**Район буенча күпьеллык үләннәр 2 июльгә 6 мең гектардан артык мәйданда чабылып, 7 мең тоннадан артыграк коры печән запасы тупланды һәм бу узган елның шул чорындагыдан шактый артыграк. Шул ук вакытта «Таң»да, МСОның ярдәмче хуҗалыгында, «Игенче»дә күпьеллык үләннәрнең яртысы да чабылмаган әле, шуңа күрә аларда әзерләнгән азык берәмлеге бер центнерга да тулмавы гаҗәп түгел.**

**Витаминлы үлән оны запасы да нигездә бер үк хуҗалыклар исәбенә арта бара. Ай башына Мичурин исемендәге, Синдряков исемендәге, «Заветы Ильича», «Кондырча», Хафизов исемендәге, «40 лет Победы» хуҗалыкларында бу төр азык 20 - 30 тонна бар инде. «Норлат» агрофирмасы составындагы хуҗалыклар яфрак азыкны аеруча күп туплап куйдылар. Бу төр азык «Алга»да 30 тонна һәм ул яктан алар шефлары - УТТ коллективына рәхмәт укыйлар. «Заветы Ильича», Синдряков исемендәге хуҗалыкларда, шикәр заводының ярдәмче хуҗалыгында витаминлы үләннәр шактый хәстәрләнде.**

**Ә менә төп азыкларның берсе булган сенаж салуга тотынган хуҗалыклар элеккечә үк биш - алты гына. Печән җыюның тоткарлануын әле ара - тирә яугалаган яңгырларга сылтарга булса да, эшнең монысын суза килүне һава шартларына сылтап акланырга урын юк.**

## ҮСЕМЛЕКЛӘР ДӘ САКЛАУГА МОХТАҖ

Басу - кырларыбызда күңелне сөендереп мул уңыш өлгереп килә. Әмма серкә очырып, башак тутырып килүче игеннәргә булган быелгы игътибарны азга гына киметсәк тә, моның нәтиҗәсе аяныч булырга мөмкин. Белгечләр фикеренчә, бодайдагы күгәрек кенә дә уңышның 25 - 30 процентына зыян салырга мөмкин икән. Башка культуралар да үсеш чорының теләсә кайсы вакытында агротехник карау һәм игътибар таләп итә. Шуны истә тотып, «Агрохимсервис» АҖ каршындагы махсус звено үсемлекләр шытканчы һәм шыткач даими рәвештә басу - кырларны эшкәртү белән мәшгуль.

Шушы чорда 40 мең гектарга якын мәйдан эшкәртелде. Аерым алганда, шикәр чөгендере гербицидлар белән эшкәртелгән. Бу культурага вегетация буенча да дару сиптерә торалар. Бөртекле сабан культуралары гербицид һәм инсектицидлар ярдәмендә агула.

Германиядә чыгарылган «Пума - супер - комби» гербицидының соңлап кайтуы эшкә тискәре йогынты ясау сәбәпле, бу нәтиҗәле агу белән нибары 2,5 мең гектар мәйдан гына эшкәртергә өлгерелде.

Хәзер районда үсемлекләрне корткычлар һәм төрле авырулардан саклау эше киң җәелдерелгән. Югыйсә, борчакка борчак борчасы, трипс зур зыян салырга мөмкин. Бөртекле сабан культураларына күгәрек һәм кузаклы борча, трипслар бик зыянлы.

- Бу авыруларга каршы көрәшү өчен чаралар җитәрлек, - ди үсемлекләрне саклау станциясе начальнигы И.Ухванов.

«Альта» фунгициды, имнант корткычларга каршы кинемекс һәм децис кебек препаратлар бик нәтиҗәле икән. Әлегә алар районда җитәрлек күләмдә тупланган. Бодайның 30 меңләп гектары шулар белән эшкәртелгән дә инде.

Гомумән, кырларда үсемлекләрне саклау буенча эш бер генә көнгә дә тукталмый. Бу эшне көйле алып баруның зур өлеше механизаторлардан тора. Хуҗалыкларда булганда ЛТЗ - 55 тракторына тагылган француз бөркегечләре белән басуда агу сиптерүчеләрне еш күрергә мөмкин. Әнә, Әгъдәс Әхмәдиев берүзе күпме мәйданда эш башкарды! Яисә Минталип Газизовны алыйк... Минкасыйм Сәмигуллин, Илдар Яруллин кебек механизаторлар да бу катлаулы, зур физик көч, түземлелек таләп итә торган хезмәтне җиренә җиткереп башкаралар. Агрегатларны су белән тәэмин итүче Сергей Алипов һәм Ренат Рахманкулов та ал - ял белән санашмыйлар. Гаиләләреннән аерым яшәп, кайчак иртәнге өчтән торып кара төнгәчә эшләргә туры килә үзләренә. Шулай итмәсәң, игеннәргә файда түгел, киресенчә, зыян килергә мөмкин икәнлеген яхшы беләләр бит алар.

Кыскасы, кырларда эш дәвам итә. Бу - уңышны күбрәк җыеп алу мөмкинлеге арта дигән сүз дә бит.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## ГАИга -61 яшь

### ШУНДЫЙ ДАТА БАР

Традиция буенча юлларда тәртип саклаучылар 3 нче июльдә ГАИ туган көнне билгеләп үтәләр. НКВД системасында бу служба оештырылганга 61 ел узды. Юл хәрәкәтенең беренче типовой кагыйдәләре 1940 елда расланды, ә беренче бердәм юл хәрәкәте кагыйдәләре 1961 елда кертелде. Безнең районда ГАИ оештырылу тарихы 1948 елга туры килә. Аның беренче начальнигы Николай Антонович Ястребов иде. Соңрак бу службаны Г.Әшрәфуллин, П.Григорьев, Б.Хәмитов, Т.Ибраһимов җитәкләделәр.

Бу елларда Октябрь эчке эшләр бүлегенең Дәүләт автоинспекциясе службасы зур үзгәрешләр кичерде.

Һәр елны ГАИ хезмәткәрләре 500 км.дан артык юлларны тикшерәләр, еллык техник карау вакытында 10000 ләп транспорт тикшерелә, 100ләп юл билгесе урнаштырыла. 6 айда гына да ГАИ тарафыннан 5000 нән артык юл хәрәкәте бозу очрагы ачыкланды, 100дән артык җинаять ачылды.

(Ахыры 2 нче биттә).

## Газлы булабыз бит, әй!

Безнеке кебек ерак төбәк - район читендәге Әмзәгә табигый газ килеп җитәр дип башыбызга да китермәгән идек. Газета - радиодан теге яки бу авыл халкы газдан файдалана икән дигән хәбәрләрне ишеткәч тә, безгә андый бәхетләр тәтемәс инде ул, дип көрсенеп куя идек. Һәм бу табигый да иде: замана авыр, хуҗалыгыбызның матди - финанс хәле дә катлаулы...

Шөкер, бүген авылыбызны газлаштыру эшләре башланды. Шәхсәнә үзебезнең йортыбызның эчке өлешенә кертелде дә инде торбалар. Авыл буйлап та сузыла килә алар. Моңа без чын күңелебездән шатланабыз: шулай булмый ни, бөтен гомеребез утын әзерләп, мич ягып, көл түгеп үтте бит. Инде, ниһаять, картлык көнебезне табигый газдан файдаланып үткәрербез, дип торабыз, ходай язган булса.

Шуңа да район җитәкчелегенә, шәхсән районыбызның хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллинга, «Газпромстрой» СМУсына шушы авыр заманда да авыл халкы өчен уңайлыклар тудыру турында кайгыртучанлык күрсәтүләре өчен бөтен авыл халкы исеменнән чын күңелдән рәхмәт белдерәсем килә һәм бу юнәлештә бара торган эшне уңышлы төгәлләүләрен телим.

**В.МИНАПОВА,**
**пенсионер.**
**Иске Әмзә авылы.**

*Авыл: Кичә. Бүген. Иртәгә.*

# БЕРЕНЧЕ КОЙМАК ТӨЕРЛЕ БУЛСА ДА...

Район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе мәгълүматларыннан күренгәнчә «Сөлчә» дә малларның баш санының кимүе сиксәненче еллар уртасыннан башланган. 1986 нчы елдан 1000 нән 770 башка калган дуңгызлар. Икенче елны тагын да азайган. Узган ел исә... 358 булган. Билгеле инде, дуңгыз ите җитештерү дә сизелерлек кимегән. Хуҗалыкның ит сату заданиесен үтәп җиткерә алмавына да шул сәбәпче булган. Мисал өчен, узган ел хуҗалык заданиесен 68 процентка гына үти алган. Шуның нибары 15 процентын дуңгыз ите тәшкил иткән.

Гомумән, дуңгызчылыкта нинди күрсәткечкә тотынсаң да, аның һәркайсы уртача район нәтиҗәләреннән күпкә кайтыш булуына төшенәсең.Шуңа да хуҗалыкны «Агрохимсевис» АҖе ярдәмче хуҗалык итеп алуының беренче көнендә үк җитәкчеләр бу тармак буенча экономик күрсәткечләрне кулларына алып һәм тәнкыйть күзлегеннән чыгып анализлап, дуңгызчылыкта эшне кискен үзгәртү буенча конкрет бурычлар куялар. Беренче планга биналар мәсьәләсе куела. Аларның берсе генә дә, менә бу ичмасам чын-чынлап мал асрарлык дип әйтерлек булмый. Шуңа да кыш булуга да карамастан, абзарларның барысында да ремонт үткәрү буенча җанлы эш башлана. Ана дуңгызлар асрала торган төп биналарның берсе «туңдырылган» хәлдә, сусыз була.Январь аенда төзәтелә ул, хәтта буяу-агарту эше дә тоткарланмый. Икенче бер бинада тагын шундый ук ремонт үткәрелә.Шунда ук лагерь төзү мәсьәләсе дә хәл ителә.

Биналар әзер булгач, хезмәтне яңача оештыруга алыналар биредә.Югыйсә, элегрәк һәр анадан өч дуңгыз баласы аламы, 7 ме,авылдагы һәр кеше кебек үк терлекче дә эшләп алынган хәләл акчасын яртышар ел ала алмый азаплана иде. Шуңа да яңача эшли башлагач, терлекчеләрнең хезмәт нәтиҗәләре белән кызыксынуын арттыру максатында, аларга эшләгән өчен һәр айның хезмәт хакын бирүдән тыш, натуралата түләү мөмкинлеге булуы турында да контракт төзелә.Икенче төрле итеп әйткәндә, һәр анадан 6 дан артыграк бала алганда, калган үрчем терлекченең үзенә калдырыла.Контракт нигезендә хуҗалык администрациясе дуңгыз карауччыны терлек азыгы һәм бина белән тәэмин итә. Без фермада очраткан Наталья Владимировна Седова да шул принцип нигезендә эшләүчеләрнең берсе булып чыкты.

- Әлегә эшемнән канәгать түгел,-диде ул безгә теләр-теләмәс кенә,-бу балалатуда теләгән максатыма ирешә алмадым: баштарак малларның яшәү шартлары комачаулады моңа, соңрак зооветеринария таләпләре...

Нишләмәк кирәк, коймакның беренчесенең төерле булуы да әллә ни гаҗәп түгел.Әмма җитәр бер көн һәм «Сөлчә» терлекчеләре килешүләрен үтәр өчен барысын да эшләрләр. Әлфия Зайчикова, Сергей Емельянов һәм Валентина Елисеева,Александр Шувалов группасында да булыр ул үрчем.

-Кызыксындыру булгач, ай саен хезмәт хакын алып торгач,ничек итеп эшләмисең ди инде,-диләр терлекчеләр үзләре. Хәзер хуҗалыкта дуңгызчылыкны күтәрүгә юнәлдерелгән бөтен эш- малларны ашату режимын камилләштерү,яшәү шартларын яхшырту, нәсел эшенә, зооветеринария таләпләренә игътибарны арттыру-ахыр чиктә барысы да фермада эшнең нәтиҗәлелеген күтәрү, маллардан үрчем алуны арттыруга юнәлдерелгән.Шул уңайдан «Агрохимсервис» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Х.Х.Морадыймов фикерен дә белештек без.

- Иң элек дуңгызларның баш санын элеккеге дәрәҗәгә җиткерергә кирәк.Бу балалатуда барлыгы 600 баш дуңгыз алдык, икенчесендә тагын шул кадәр үрчем алсак, моңа ирештек дип санарга була.Аннан инде киләчәктә дәүләткә сатыла торган итнең яртысы күләмендә дуңгыз ите тапшыру буенча реаль планнар да корып була,-диде ул.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## ГАИга -61 яшь

# ШУНДЫЙ ДАТА БАР

( Ахыры. Башы 1 нче биттә).

Район автохуҗалыкларында һәм мәктәпләрдә ГАИ хезмәткәрләре тарафыннан юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча 120 чыгыш ясалды, балалар арасында юлда имгәнүләрне кисәтү буенча 20 төрле чаралар уздырылды. Хәрәкәт куркынычсызлыгы күп очракта автомобиль юллары торышына да бәйле. Хәзерге вакытта районда 450 км.дан артык юл һәм 42 күпер бар. Сер түгел, соңгы елларда сыйфатлы юллар төзүгә игътибар кимегән иде. Район хакимиятенә яңа җитәкче килгәч, хәл бөтенләй үзгәрде. Агымдагы елга гына да юллар төзү, булганнарының сыйфатын яхшырту, күперләр төзү буенча зур эшләр планлаштырылды. Каравыл Тавы янында Чирмешән аша салынган күпер юл хәрәкәте өчен иң куркыныч урыннарның берсе булып кала килде. Хәзер Зәй күпер төзүчеләр отряды биредә яңа күпер сала. Норлат - Чистай юлының күпердән соңгы куркынычлы участокларын да хәвефсезрәк иттереп турылау өчен әзерлек эшләре бара. Беръюлы берничә юнәлештә эшләүче «Татавтодор» юл төзү оешмасы Мамык - Базарлы Матак юлының Кычытканлы борылышы тирәсендәге участогын киңәйтү белән дә мәшгуль. Норлат - Дала Мамыгы юлын киңәйтеп асфальтлау, Бутаиха белән Тимерлек арасында туры юл салу шулай ук юлчыларга күп уңайлыклар китерәчәк. Моннан тыш юл ремонтлау - төзү участогы тимер юл өстеннән уза торган күперне төзекләндерү эшләрен тәмамлап килә, НУАД ГАИ бүлеген, оборона - спорт техника җәмгыятен, техник хезмәт күрсәтү станцияләрен төп трасса белән базарны читләтеп тоташтыручы аерым юл сала. НГДУның юл төзү бүлеге Норлат - Кузайкино юлын киңәйтү белән дә шөгыльләнә.

Шулай итеп, санап кителгән барлык бу эшләрне уңышлы төгәлләү юлларның сыйфатын яхшырту буенча җыелган проблемаларны хәл итәргә, шул рәвешле районның халык хуҗалыгына ышанычлы транспорт хезмәте күрсәтү дәрәҗәсен күтәрергә мөмкинлек бирәчәк, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итәргә булышачак. Бер үк вакытта әле Норлат эчендәге юлларны төзекләндерү, тротуарлар төзү буенча күп эш башкарасы бар. Бу уңайдан шәһәрдә юл билгеләренең тиешенең чиреге кадәр генә булуын әйтү дә җитә. Автобус тукталышларын тиешле тәртипкә китерү буенча да эшне дәвам иттерергә кирәк. Ул мәсьәләләрнең хәл кылынуы шәһәр халкының төрле микрорайоннар арасында ышанычлы автобус элемтәсе булуына, җәяүлеләр хәрәкәтенең хәвефсезрәк булуына һәм юлда имгәнүләрнең кимүенә өметләрен акларга мөмкинлек бирер иде.

Автотранспорт инспекциясе службасы алдына куелган җаваплы бурычларны үтәү хәлиткеч дәрәҗәдә хезмәткәрләребезнең оешканлыгына, дисциплиналылыгына һәм югары һөнәри сыйфатларына да бәйле. Хезмәткәрләребезнең күпчелеге бу таләпләргә җавап бирә. Андыйлар арасында техник күзәтү буенча өлкән инспектор милиция капитаны З.Хөснуллин, администатив практика буенча инспектор лейтенант Шәйхетдинов, имтихан участогы инспекторы өлкән лейтенант Р.Әюпов, юл - транспорт службасының өлкән инспекторы лейтенант Н.Гайнетинов, юл күзәтчелеге буенча инспектор капитан А.Каюмов бар. Бүген ГАИ службасы өчен автоюлларда кешеләр гомере һәм сәламәтлеге сагынлда торудан да мөһам бурыч юк.

**Х.ӘЮПОВ,**
**район эчке эшләр бүлегенең ГАИ начальнигы, ТР атказанган транспорт хезмәткәре.**

Юл төзүчеләр өчен, кем әйтмешли,урак өсте бүген: җәй юл төзү-ремонтлау өчен иң кулай чор. Шуңа да юл төзүчеләр тәннәрен көйдереп алучы кояшлы көндә дә, чамалы гына янгыр яуганда да эшләрен ташламыйлар. Норлат автомобиль юллары идарәсенең сез рәсемдә күргән эшчеләре дә вакыт белән һичкайчан санашмыйлар. Борис Варламов-автогрейдерчы, Николай Гаврилов бульдозерчы, Николай Левинов тракторчы. Һәр өчесе дә җаваплы хезмәттә. Геннадий Савгачев белән Илсур Даутов-юл эшчеләре. Николай Иванов һәм Нияз



Минголов- шоферлар. «КамАЗ» автомашиналары белән объектка асфальт-бетон ташыйлар алар. Мастер Виктор Багаев исә тулаем коллектив эшен оештыру өчен җаваплы.

Бүген әлеге егетләр Норлат- Әлмәт юлында капиталь ремонт үткәрү белән мәшгульләр.

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

# Дөньяда ниләр бар?




Россиянең «Мир» орбиталь комплексында гайре табигый хәл булды. «Прогресс М-34» транспорт-йөк кораблен тоташтырган вакытта эш режимы бозылды һәм тонна ярым авырлыктагы корабль «Мир» станциясенә килеп бәрелде. Нәтиҗәдә «Спектр» модуленә зыян килде. Космонавтлар Василий Циблиев, Александр Лазуткин һәм Америка астронавты Майкл Фоэл бу вакытта «Союз» кораблендә иде. Аларның тормышы өчен куркыныч юк.

***

Украинаның Волын, Львов, Ровно, Закарпатье, Тернополь һәм Хмельницкий өлкәләре территорияләрендә көчле давыл ике көн дәвам итте. Аерым урыннарда җилнең көче сәгатенә 80 километрга җитте. Якынча мәгълүматларга караганда 9 кеше үлгән, 46 кеше яраланган. Шундый ук көчле давыллар Белорусьның Минск һәм Брест өлкәләренең көньяк районнарында да кабатланды.

***

Приморьеда яшәүчеләр хезмәт хакын вакытында түләмәүгә ачулары чыгып, 1 июльдән Трансебер тимер юл магистрален блокадага алырга ниятлиләр. Тимер юлдагы пикетны бер генә товар яки пассажир поезды да үтеп китә алмаячак.

# ҖИҢЕЛМӘС КОҢГЫЗ



**Сорау - җавап**

***«Ел саен бәрәңгене колорадо коңгызы баса. Шушы афәттән котылу өчен берәр чара уйлап чыгаралармы инде галимнәр, юкмы? Язсагыз иде шул хакта.***

**Ахунов. Казан».**

Галимнәр дә җиңә алмаган бу корт бәрәңгенең яңа чыккан яфракларына 240 ка якын күкәй сала. Температура торышына карап, алардан 16-24 көндә личинкалар чыга. Елына дүрт буын зарарлы бөҗәк үсеп җитешә.

Колорадо коңгызына каршы ничек көрәшергә? Көздән туфракны тирән итеп эшкәртү кышлауга әзерләнгән бөҗәкләрнең 70 процентын юк итә. Ә язын бәрәңге утыртып беренче яфраклар күренүгә килгән бөҗәкләрне тоз яки киросин салынган савытка җыеп алырга кирәк. Бәрәңге участогының 10 процентын колорадо коңгызы басса, агулы препаратлар сиптерү мөһим. Беренче мәртәбә массовый агулау икенче буын коңгызлар чыккан вакытта отышлы. Кирәк булса, нәкъ шул ук препарат белән 6-8 көннән соң яңадан эшкәртергә ярый.

Коңгызларга каршы көрәштә бүтән төрле чаралар да кулланыла. Мәсәлән, мич көле бик нәтиҗәле. Утыртканда бәрәңге орлыгын көлдә манчып алырга кирәк. Аннары коңгызлар күренә башлаганчы, үсентеләргә көл эремәсе сиптерсәң: 2 литрлы банка белән көлне бер чиләк суга салып ,40 грамм кер сабыны эремәсе өстисең дә, барлыкка килгән массаны 10 литр суга кушасың һәм бәрәңгегә сиптерәсең.

***Әрем.*** 150 грамм туралган әремгә һәм 1 стакан агач көленә кайнар су салып, 2-3 сәгать төнәтәсең һәм сибәсең.

Суган кабыгы төнәтмәсен (1:5) коңгыз күкәй сала башлаганчы сибү әйбәт. Коңгызларны куркыту өчен бәрәңгенең рәт араларына сарымсак, ногыт борчагы, житен утыртырга мөмкин.

Коңгызлар өчен тозак куярга була. Пыяла һәм калай савытларның эчке ягына бәрәңге суы сөртеп, төпләренә берничә бәрәңге телеме салып куярга кирәк. Мондый савытларны 5-7 кв. метрга берне урнаштырыгыз һәм җыйналган коңгызларны даими рәвештә үтерә барыгыз.

Битоксибациллин дигән бактериаль препарат та бик файдалы. 10 литр суга 50-70 грамм препарат җитә. Күпләп личинкалар күренә башлаган чорда сиптерү әйбәт. 7-8 көн саен 2-3 мәртәбә эшкәртергә кирәк.

**99 нчы профессиональ училище 1997-98 елларга яңа белгечлекләр буенча укучылар туплый:**

**1. Усадьба хуҗасы. Уку срогы -3 ел, тулы булмаган урта мәктәп базасында.**

**2. 3 класслы тракторчы-машинист. Уку срогы -6 ай, уку түләүле.**

**3. «В» категорияле машина йөртүчеләр. Уку срогы -4 ай. Уку түләүле.**

**4. «В» категорияле шоферлар. Уку срогы- 2ай. Уку түләүле.**

Барлык сораулар белән училищеның кабул итү комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә. Адрес: Гыйматдинов урамы, 48.

**Администрация.**



***ОСТО ның Октябрь район Советы түбәндәге категорияләр буенча укучылар җыя:***

**«АВ»-уку срогы1,5 ай.**
**«ВС»-3,5 ай.**
**«ДЕ»-1 ай.**

## Кем булырга? Кайда барырга?

# Лаешта бар бер техникум



Төз көмешсыман чыршылар уртасына, гүзәл Кама ярына урнашкан безнең техникумның укыту һәм иҗтимагый-көнкүреш корпуслары, тулай торагы. Биредә бухгалтерлык учеты, прогнозлау һәм анализ, хокук белеме буенча белгечләр укый. Техникумда көндезге һәм читтән торып уку бүлекләре бар.

Барлык бүлекләрдә 900 дән артык студент укый, 40 укытучы белем бирә. Студентлар карамагында иркен, якты уку кабинетлары һәм лабораторияләр, видеокласслар актлар һәм спорт заллары, ашханә, уку залы белән китапханә, 2 компьютер классы бар. Барлык студентларга да тулай торактан урын бирелә, анда яшәү һәм ял итү өчен әйбәт шартлар бар.

Һәр елны техникум 270 ләп яшь белгеч әзерләп чыгара. Училищены «4» һәм «5» билгеләренә тәмамлаучылар Казан авыл хуҗалыгы академиясенә керү имтиханнарыннан башка белем бирүнең кыскартылган программасы буенча кабул ителәләр. Техникумны тәмамлап чыгучыларның 30 сы «Республиканың атказанган экономисты» исемен йөртәләр.

Уку срогы: 9 класс базасында 2 ел да 10 ай, көндезге бүлектә 11 класс базасында-1 ел да 10 ай, читтән торып уку бүлегендә-2 ел да 8ай.

Көндезге бүлеккә гаризалар кабул итү 5 августка кадәр. Читтән торып уку бүлегенә 10 августка кадәр. Көндезге бүлеккә керү имтиханнары 15 июльдән, читтән торып уку бүлегенә- 10 июльдән башлана.

**А.САТДИНОВ,**
**Лаеш авыл хуҗалыгы техникумының директор урынбасары, ТРның атказанган экономисты.**

## Норлат шәһәр электр челтәре соңгы вакытта электр тогы сугу нәтиҗәсендә бәхетсезлек очраклары ешаюга игътибар юнәлтә

1996-97 елларда Актаныш районы, Бөгелмә, Югары Ослан, Казан шәһәре электр челтәре хуҗалыклары объектларында үлем яки авыр җәрәхәт белән тәмамланган шундый очраклар булды. Шуларны истә тотып, шәһәр электр челтәре Норлат шәһәре халкын югары вольтлы һава линияләрен саклау зонасында, түбән вольтлы һава линияләре, трансформатор подстанцияләре тирәләрендә сак булырга чакыра.

Һава линияләрен Саклау зоналарында һәм трансформатор подстанцияләре янәшәсендә үз белдегең белән төзелеш алып бару һәм төрле материаллар өю тыела. Трансформатор подстанцияләренә 2 метрдан да якын килмәскә, койма эченә кермәскә. Чыбык өзелгән һәм ул җиргә тигән очракта бу урынга 8 метрдан ( югары вольтлы булганда) яки 2 метрдан ( түбән вольтлы булганда) якын килмәскә.

Ата-аналарның балалар арасында аңлату эшләре алып баруын сорыйбыз. 22 май көнне 1 сәгатьтә хәрби комиссариат янында 11 яшьлек Куркин Иван бәхетсезлек очрагына дучар була: югары вольтлы электр линиясенә кагылып торган агач башына укны җибәрә дә аны алырга менеп китә. Агачның дымлы өслеге аша малайга ток бәрә, ул агачтан егылып төшә. Иванга беренче ярдәмне аны очраклы рәвештә күреп алган хәрби комиссариат шәфкать туташы күрсәтә. Бары шуның нәтиҗәсендә генә бала исән кала. Врачлар диагнозы: баш мие селкенү, сул балтыр һәм беләзектән куллар 2-3 дәрәҗәдә термик пешү.

Хөрмәтле ата-аналар, балаларны трансформатор подстанцияләренә якын килүдән, икенче катка менүдән, йозакларга кагылудан, ишекләрне ачудан, ток үтә торган өлешләргә, тимер-бетон баганалар чыбыкларына һәм аларның металл өлешләренә кагылудан тыегыз, һава линияләре янәшәсендәге агачка үрмәләргә рөхсәт итмәгез.

Шәһәр электр челтәре халыкка мөрәҗәгать итә: һава челтәрендә, трансформатор подстанцияләрендә нинди дә төгәлсезлек күргәндә, тиз арада 2-11-36, 2-19-80 телефоннары буенча дежур электр монтерына хәбәр бирегез.

# КОТЛЫЙБЫЗ!



*Югары Норлат авылында яшәүче кадерле* ***әтиебез Нургали Мортаза улы, әниебез Миннеруй Әһлиулла кызы Мөхәммәтовларның*** *3 нче июльдә алтын туйлары.*

*Юбилеегыз белән котлап, әткәй-әнкәй.*

*Без телибез сезгә иң элек*
*Ныклы саулык, бәхет, озын гомер,*
*Бөтен гаиләбезгә иминлек.*
*Авырлыклар, кайгы, авырулар*
*Урап үтсен безнең өй эчен.*
*Дөнья күге һәрчак аяз булсын*
*Һәм уң килеп торсын һәр эшегез.*

***Иң изге теләкләр белән улыгыз, кызларыгыз, киленнәрегез, онынкларыгыз, туганнарыгыз.***

## Белдерүләр

### Сатабыз

**«Альянс» кибете 2-3 камералы «Норд» суыткычлары сата, (бәясе шәһәрдә иң арзан-2000000 сум). Октябрь районы һәм күрше районнарда өйгә китереп бирә. Шикәр комы, капчыгы-210000 сум. Лицензия 700803/1.** Тел.: 5-24-97.

***

**1996 елгы тентланган «Газель»**. Тел.: 2-27-55.

***

**Балалар өчен бассейннар.** Тел.: 2-27-55. 273 номерлы таныклык.

***

**Норлат сәүдә базасында арзан бәягә түмәрләр һәм ваклап зәңгәр, яшел, сурик, идән өчен коңгырт, фасад өчен ак краскалар, газлы сулар.**

***

**Яңа «ИЖ-Планета-5», бәясе-килешү буенча.** Адрес: Дружба ур., 4-1, тел.: 5-29-53.

***

**Йорт**. Пионерская ур., 12 йортка 17 сәг. соң мөрәҗәгать итәргә.

***

**«Мечта» бакчачылык ширкәтендә дача. Кыйммәт түгел.** Карл Маркс ур., 2-28.

***

**Йорт**. Московская ур., 14-2.

***

**Чехословакиядә эшләнгән мини трактор.** Тел: 5-29-51, 17 сәг. соң.

***

**Шикәрчеләр поселогында гараж.** Тел.: 2-16-79.

***

**1994 елгы ВАЗ-2106.** Адрес: Лермонтов ур.,37.

***

**Яхшы хәлдәге ИЖ-Юпитер 4, «Рабица» сеткасы. Кыйммәт түгел**. Тел.: 5-15-89.

### Төрлесеннән

**Яшәп тору өчен шәхси йорт кирәк**. Тел.: 2-15-63.

***

**Шәһәр уртасындагы 2 бүлмәле фатир өстәмә түләп 3 яки 2 бүлмәлегә алмаштырыла. Шикәрчеләр һәм Кормыш поселокларыннан тәкъдим итмәскә.** Тел.: 2 - 27 - 55.

***

**1 бүлмәле фатир өстәмә түләп 2 бүлмәлегә алмаштырыла.** Тел.: 65-7-30.

***

**Яшәп тору өчен телефонлы фатир кирәк.** Тел.: 2-19-76, 16 сәг.кә кадәр.

***

**3 бүлмәле фатир 2 һәм бер бүлмәлеләргә алмаштырыла**. Адрес: Советская ур., 183-103, 18 сәг.тән соң.

***

**Бурычка акча алабыз.** Тел.: 2-13-49.

**«Октябрь «Сельхозтехникасы» АҖ енә даими эшкә токарьлар, фрезерчылар, эретеп ябыштыручылар, монтажчылар, шлифлаучылар, шоферлар, электриклар, аккумуляторчылар, автоэлектриклар, суыткыч җайланмаларын көйләүчеләр, 20-22 яшьтән дә ким булмаган суыткыч җайланмаларын көйләү буенча өйрәнчекләр, компрессорчылар кирәк. Түләү -эш башыннан - премиаль.**

Предприятиенең кадрлар бүлегенә мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 2-17-24.

Бикүле урта мәктәбе коллективы әтисе үлү сәбәпле өлкән укытучы **Галиуллина Зөлфия Хәбибулловнаның** тирән кайгысын уртаклаша.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2306 данә. Заказ N 7207